Олы Әтнә урта гомуми белем бирү мәктәбе

**Республика күләмендә үткәрелгән семинар**

# ***“ Г.Исхакыйның «Кәҗүл читек” әсәрендә милли йолаларның чагылышы”***
# ***(7нче сыйныфта әдәбият дәресе)***

**Үткәрде: Сабирҗанова Светлана Илдус кызы**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Дәрес темасы:**

Г.Исхакыйның «Кәҗүл читек"хикәясендә милли йолаларның чагылышы.

**Дәреснең максаты:**

1. Әсәргә өлешчә анализ ясап, башка образларга мөнәсәбәттә Әхмәдулла образын ачу, образлар арасындагы бәйләнешләр һәм символлар аша әсәрнең эчтәлеген ачу, әсәрнең актуальлеген күрсәтү;
2. Укучыларны нәтиҗәләр чыгарырга, системага салырга, иҗади уйларга өйрәтү;
3. Милләтебез гореф-гадәтләренә, йолаларына хөрмәт, милли горурлык, сакчыллык, белемгә омтылыш тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Г.Исхакый әсәрләреннән күргәзмә, әдипнең портреты, презентация(Әхмәдулланың киемнәре,характеры турында), "Татар исемнәре ни сөйли" сүзлек.

**Дәрес барышы:**

**I Оештыру.**

- Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар! Хәерле көн, укучылар! Татар әдәбияты дәресен башлыйбыз.

**II Актуальләштерү.**

**Укытучы.**- Узган дәрестә без сезнең белән Г.Исхакый иҗаты белән танышкан идек. Аның иҗатын өйрәнүне дәвам итәбез.Бүгенге дәрестә Г.Исхакыйның милләтебезне юкка чыгудан саклап калырга ярдәм итүче иң күренекле әсәре - "Кәҗүл читек" әсәре турында сөйләшербез. Дәрескә эпиграф итеп түбәндәге юлларны алырбыз.

Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәннәрне онытма син.
Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен.
Нинди уйлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.
Р.Фәйзуллин.

Укучылар, сез өйдә әсәрне укып килергә тиеш идегез. Һәм эзләнү өчен темалар тәкъдим ителгән иде. Дәрес барышында без ул темаларга мөрәҗәгать итәрбез.

**Слайдта темалар күрсәтелә.**

1. Милләтебезнең дини бәйрәмнәре.
2. Читек тарихы.
3. Татар исемнәре ни сөйли?
4. "Кәҗүл читек "әсәренә охшаган нинди әсәрләр укыганыгыз бар?

**Азан тавышы тыңлана.**

**Слайдта күрсәтелә.**

Авылыбызда гүзәл мәчет,
Калкып чыкты бер заман.

Иманга дәшеп халыкны,
Яңгырый моңлы азан.

Укучылар,ничә еллардан бирле Әтнәбездә  милләтебезнең гимны булып азан яңгырый.Ул безне бары тик изгелекләр генә эшләргә дәшә сыман.Туган авылыбызда һәрвакытта да азан тавышы яңгырап торсын.

- Укучылар, милләтебезнең нинди дини бәйрәмнәрен беләсез?
- Ураза гаете -  Рамазан аенда ураза тоту – кешеләрнең иң яраткан, көндәлек гадәтеннән аерылып, ашамый, эчмичә генә тору түгел, ә шул изге Коръән иңгән айда гөнаһлы эшләрдән дә тыелырга, күңелне пакландырырга һәм күбрәк яхшылыклар эшләргә дәрт арттыра. Рамазан аенда күңелләр чистара. Ураза тоту кешеләрне бер-берсенә якынайта. Бердәмлек арта. Мөселманнар бергәләшеп мәчетләргә намаз укырга баралар.Күптән түгел генә узган ураза гаетенә мин дә әти белән мәчеткә бардым.Анда вәгазь тыңладык, сәдака салдык.Без кайтышка әни коймак пешереп торган иде. Бергәләшеп тәмле әйберләр белән чәй эчтек
- Кадер киче -  бу мөбәрәк айның бер изге кичәсе бар, аны кадер киче дип атыйлар. Дөньядагы бар мөселманнар бу кичәдә, күбрәк  намазлар укыйлар, мәчетләргә баралар, садакалар бирергә тырышалар. Мөселманнар, тормышта булган сынаулар аркылы чыккан дошманлыкларны бетереп, бер-берләрен гафу итеп, туганлыкны һәм дуслыкны яңартырга тырышалар. Бу изге көннәрдә туганнарны, күрше-тирәне җыеп  ифтар мәҗлесенә кунакка чакыралар (авыз ачтыралар).

Корбан гаете - зөлхиҗҗә аеның унынчы көнендә уздырыла. Ул көнне мөмкинлеге булган кешеләр  корбан чалалар.
Корбан бәйрәмендәге матурлыкларның берсе – гаед көненең таң ату вакыты белән мөселманнар Аллаһны олуглап, тәкбирләр әйтеп, бергәләшеп мәчетләргә баралар

Бәрәат кичәсе (бәхет, изгелекләр иңә торган көн) - шагъбан аеның 15 нче кичәсен Бәра'әт кичәсе дип атыйлар. Бәрәат дигән сүз пакълык, гаепсезлек, котылу дигән мәгънәдә килә. Бу кичәне бәрәкәт кичәсе дип йөртәләр. Чөнки бу кичәдә Аллаһ тәгалә фәрештәләргә бәндәләрнең ризыклары турысында хәбәр бирә икән, кемгәдер уңыш, байлык, ә кемгәдер ярлылык килер. Мөселманнар бу кичтә Аллаһтан үзләренә, туганнарына, якыннарына хәерле ризык, саулык, сәламәтлек, уңышлар сорап дога кылып уздыралар.

Гарәфә көне - зөлхиҗҗә аеның тугызынчы көне - мөселман календаренда Аллаһ тарафыннан мөселманнар өчен сайланган көннәрнең арасыннан олы итеп танылган. Бу көнне олуг хаҗ гыйбәдәтен кылучылар Гарафә диелгән җирдә Аллаһка дога кылып уздыралар. Бу- гает алды көне.
Гарафә көне генә түгел, ә Зөлхиҗҗә аеның беренче тугыз көне

мөселманнар өчен тулы бәрәкәт. Бу көннәрдә изгелекләр кылып, ураза тотып уздыру саваплы эшләрдән санала.
Бигрәк тә Аллаһ каршында 9 нчы көн олы вә зур савапларга ирештерә торган итеп танылган.

**Укытучы.** Г.Исхакыйның “Кәҗүл читек” әсәрендә нинди бәйрәм турында сүз бара?

**Укучы.** Гает бәйрәме турында.

**Укытучы.** -Нинди бәйрәм соң ул гает бәйрәме?

**Укучы.** Гает бәйрәме- ислам диненең иң зур бәйрәмнәреннән берсе.Бу бәйрәм рамазан ае тәмамлангач билгеләп үтелә. Бу айда кешеләр ямьсез сүзләрдән,ялганнан, кеше сөйләүдән тыелырга тиеш, начар эшләр эшләмәскә, олыларга хөрмәт, кечкенәләргә мәрхәмәт күрсәтергә тиеш.

Чыннан да, укучылар, дини бәйрәмнәребезне олылыйк, ислам дине безне һәрвакыт яхшылыклар гына эшләргә өйрәтә.Гомумән, бәйрәм көнне генә түгел, һәрвакыт әти-әниләрегезгә игелекле булыгыз,изгелекләр эшләргә тырышыгыз. Кешеләргә эшләгән изгелек җирдә ятмый, үзеңә үк изгелек булып әйләнеп кайтачак.

**III Төп өлеш**

**Укытучы.**Ә хәзер “Кәҗүл читек “ әсәренә күчик.Әсәр нинди жанрга карый?

**Укучы.** Хикәя жанрына, чөнки әсәрдә Әхмәдулла белән булган бер генә вакыйга турында сүз бара.

**Укытучы.** Ә хәзер сүзлек өстендә эш. Сүзлек дәфтәрләренә язып куябыз.

**(Слайдта күрсәтелә)**

Кәҗүл читек – кәҗә тиресеннән эшләнгән читек

Сауры – ат тиресеннән эшләнгән күн

Зияб – кызылтүш

Сахтиян – сарык һәм кәҗә тиресеннән эшләнгән күн

Саранҗы – саржа( тукыма)

Айбагар – көнбагыш

Ә хәзер хикәянең кыскача эчтәлеген сөйлик.
(Бер укучы хикәянең эчтәлеген сөйли)

Укучылар, хикәяне ничә өлешкә бүлдегез?

**Укучы**. Хикәяне ике өлешкә бүлеп була.

**Укытучы.** Бу өлешләргә нинди исемнәр бирер идегез?

**Укучы.**1нче өлеш.”Әхмәдулланың татлы хыяллары”
2 нче өлеш “Өзелгән өмет”

**Укытучы**. Укучылар, әсәр кем исеменнән сөйләнә?

**Укучы.** Әхмәдулла исеменнән.

**Укытучы.** Мондый геройны кем дип атыйбыз?

**Укучы.** Лирик герой.

**Укытучы** . Сезгә эзләнү өчен бирелгән темалар арасында әсәрдә сурәтләнгән геройлар исемнәренең мәгънәсен ачыклап килергә иде. Сүзне укучылар сезгә бирәбез.

**Укучы.**Әхмәдулла- иң дәрәҗәле дигән сүз.

**Укытучы.** Укучылар, Әхмәдулланың портретын төзик әле?

Әхмәдулланың киемнәре:

Чапан – ямь-яшел

Чалма – чуп-чуар

Читек – кап-кара

Казаки – кыска җиңле

Кәвеш – кечкенә булгач, әбисенең яшел башмагын кия

Бу киемнәр нинди һәм нәрсә өчен хезмәт итә?(рәсемнәре күрсәтеп барыла)**Слайдта күрсәтелә.**

Чалма – мөселманнарда ( гадәттә дин әһелләрендә) ирләрнең башка берничә кат урап кия торган җиңел тукымадан гыйбарәт баш киеме.

Чапан – җилбәгәй җибәреп йөртелә торган озын чабулы халат сыман кием; бохар халаты.

Кәвеш – йомшак күннән тегелгән кунычсыз аяк киеме.

Казаки – тегелеше белән озын камзулга охшаган,ләкин җиңле һәм кечерәк кенә утыртма якалы өске кием

Читек – йомшак күннән тегелгән, юка олтанлы, озын кунычлы аяк киеме (элек аны сәхтиян күннән теккәннәр)

**Читек тарихы сөйләнә.**

**Укытучы**. Укучылар, Әхмәдулланың хыялындагы читекне тасвирлап карыйк әле.? (Укучылар читек турында сөйлиләр, аннары дәреслектән читек сурәтләнгән урыннарны табып укыйлар)

Укучылар, Әхмәдуллага кем ярдәмгә килә?

**Укучы**. Әхмәдуллага әбисе ярдәмгә килә. Ул аңа кәҗүл читек хәзерләп бирергә вәгъдә итә.Ул аны ничек үти, шул урынны тыңлап китик әле.

**Укытучы.** Әхмәдулла әбисенең читек әзерләп утыруын күргәч нинди хисләр кичерде?

**Укучы.** Ул тыныч күңел, татлы хыяллар белән йокларга ята.

**Укытучы**.Менә таң ата .Гает иртәсе җитә. Әхмәдулла татлы хыяллар белән йокыдан тора.Әйдәгез әле, Әхмәдулланы гаеткә барырга әзерләү күренешен рольләргә бүлеп укыйк.

Укучылар, сез Әхмәдулланың иптәшләре белән килешәсезме? Сезнеңчә алар дөрес эшләделәрме?

**Укучы.** Минемчә, юк, дөрес эшләмәделәр. Алар Әхмәдулланың кеше киемнәрен кигәнен күрсәләр дә сиздермәскә тиешләр иде. Берсе генә булса да якларга тиеш иде.Алар Әхмәдулланы мыскыл иттеләр, аның хисләрен җимерделәр.Алар шушындый бәйрәм хөрмәтенә генә булса да аннан көлмәскә тиеш иделәр

**Укытучы.** Әхмәдулланың характерын билгелик.(Аның образына хас сыйфатларны билгеләү.Аның мактануы сәбәбендә мулла баласы булу аркасында үзен башкалардан өстен тотуын ачыклау. Тәкәбберлек, масаю хакында фикер алышу. Әхмәдулланың холкын, психологиясен ачучы урыннарны табу, аларны уку. Әхмәдуллага характеристика бирү)

**Укучы. Беркатлы, тиз ышанучан, яхшы күңелле**

Беркатлы, олылар әйткәнгә бик тиз ышанучан, яхшы күңелле малай, дия алабыз. Ул төшенкелеккә бик тиз бирелә. Теләге тормышка ашмаганны күргәч, шунда ук утырып елый башлый. Ләкин шул ук вакытта үзен бик тиз кулга ала.

**Укучы. Теләсә нинди вакыйгадан да үзенә юаныч таба белә**

Теләген тормышка ашыру өчен кечкенә генә булса да өметкәябышып үзен юата ала. Зур читекләрне кабат-кабат киеп карый. Анысы ярамагач, әбисенең яңа читекләр тегеп бирәм диюенә дә ышана. Өметен тагын уята. Ниндидер иске читекне корымлап утыруны күргәч тә үзен юату өчен сүзләр таба. Корымга буялган читегенең яңа булмавын белә, әмма барыбер бик горурланып, яңа итеп кабул итә. Чапаны да этисенең иске чапаныннан тегелә. Ләкин Әхмәдулланың әбисе сүзләренә ышанасы килә. Иске булса да, саранҗы булгач, тиз тузмый торган өр-яңа чапан дип горурлана. Кәвешләре дә озак ятудан кибеп беткән. Аякларына сыймый. Алай да Әхмәдулла кәвешләре белән дә мактана. Аларны суга салып кую, әлбәттә, яраксызлыгын күрсәтә. Ләкин Әхмәдулла үзенең иске кәвешләренең суда булуына да, каз мае белән майлануга да яхшылык дип бәя бирә. Әхмәдулланың бөтен горурлыгы иске-москыдан корыштырылганнар. Ләкин ул аларны мактарга һәм үзен-үзе юатырга көч таба. **Теләсә нинди вакыйгадан да үзенә юаныч таба белүе — малайның күркәм сыйфаты.**

**Укучы. Мактанчык**

Ләкин шуның белән бергә ул аз гына мактанчык та. Ул үзенең эчендәге шатлыкны берәүдән дә яшерә алмый. Шатлыгы белән беренче чиратта дусты Миңлегали белән уртаклаша. Сеңлесе алдында мактана. Әбисеннән үзенең шатлыгын хуплауны көтә. Әхмәдулланың **кимчелеге — горурланасы, мактанасы килү хисенә кирәгеннән артык буйсынуда.** Әхмәдулла хикәянең ахырында да беркатлы, хисен җиңә алмый торган малай булып кала. Ул үзен үртәгән малайларга үзләренчә усаллык белән җавап бирә. Берсенең кулын тешли. Тазга ачу белән: «Таз шайтан, айбагыр карагы!», дип кычкыра. Хәзер ул кызгандыра.

**Укытучы.** Әйдәгез, Әхмәдулланың сыйфатларын уңай һәм тискәре сыйфатларга бүлик, дәфтәрләргә языйк. (Сыйфатлары презентациядә чыгып бара )

| **Уңай сыйфатлары** | **Тискәре сыйфатлары** |
|---|---|
| өлкәннәрне тыңлый, хөрмәт итә | мактанчык |
| эти-әниләрен хөрмәт итә | тәкәббер |
| беркатлы | горур |
| тиз ышанучан | тиз үпкәләүчән |
| яхшы күңелле | |
| теләсә нинди вакыйгадан да үзенә юаныч таба белә | |

**Укытучы.** Әхмәдулланың дусты Миңлегалигә, авылдаш малайларга һәм аларның Әхмәдуллага мөнәсәбәте ничек?

**Укучы.** Әхмәдулла хисенә генә буйсынып яшәүдә гаепле, билгеле. Ләкин авыл малайларының гаебе тагын да зуррак. Алар арасында ярдәмсез калган иптәшләрен яклаучы бер генә шәфкатьле кеше дә табылмый. Малайлар үртәп, кешене хур итеп тәм табалар. Аларның шатлыклары усаллыкка нигезләнгән.

Әхмәдулланың көлкегә калуына, билгеле, рәхимсез авыл малайлары да гаепле. Алар бар да шәфкатьсезләр. Елаганны дәррәү килеп кыйнарга керешәләр.

**Укытучы.** Ә сез малайлар урынында нишләр идегез?

- Әхмәдулла урынында нишләр идегез?

(Укучыларның фикерләре тыңлана)

Укучылар, әсәрдә тагын нинди йола, гореф-гадәтләр турында язылган?

**Укучы.** Бәйрәмчә ризыклар( борчак белене, кыстыбый, коймак, сумсалар, пәрәмәчләр);

- яңа киемнәр сатып алу, тегү;
- бисмилла әйтеп уң аякка, кулга кию;
- Гарәфә көнне еларга ярамый.

**Укытучы.** Ни өчен бәйрәмнәргә яңа киемнәр булдырганнар?

Нигә чапанны искедән теккәннәр, читек алып кайтмаганнар?

**Укучы.**Сакчыллык, уңганлык, булдыклылык, булганны әрәм итмәү, дин кушмый

**Укытучы.** Гарәфә көнне еларга ярамый, ни сәбәпле?

**Укучы.** Изге көн, дингә хөрмәт.

**Укытучы.** Әсәрдән тел – сурәтләү чараларын табыйк әле? Алар нәрсә өчен хезмәт итә?

**Укучы.** Алар текстның тәэсир көчен арттыра.

**Укытучы.** Укучылар, “Кәҗүл читек “ хикәясенә охшаган тагын нинди әсәрләр укыганыгыз бар?

**Укучы**. Ф.Әмирханның “Нәҗип” хикәясен.

**Укытучы.** “Кәҗүл читек” бүген актуальме?

**Укучы.** Әйе, бу проблема бүгенге көндә дә көн кадагында тора, чөнки олыларга хөрмәт, аларның сүзләрен тыңлау; үзеңдә ихтыяр көче тәрбияли белү, йолаларга хөрмәт белән карау бүген дә иң кирәкле сыйфатлар.

**Укытучы**.Укучылар, без сезнең белән һәр дәрестә олимпиадага, бердәм республика имтиханына хәзерлек алып барабыз. Мин сезгә шуның буенча иҗади эш тәъдим итәм. Г.Исхакыйның “Кәҗүл читек” хикәясендә Матурлык һәм Ямьсезлек хакында языгыз.

**IV Йомгаклау**

- **Укытучы.** Бүгенге дәрестән нинди яңалык алдың?
- “Кәҗүл читек” әсәре безне нәрсәгә өйрәтте?(мактанчык булмаска, кешеләргә ихтирамлы булырга, тәккәбер булмаска, әти-әниләрне хөрмәт итәргә, динебезгә, гореф – гадәтләребезгә инанырга, алар белән горурланырга).

**Укытучы.** Әйе, укучылар, татар язмышы, милләт язмышы тәрбияле яшьләр кулында булырга тиеш, бу очракта Әхмәдулла кулында милләт язмышы.

Дәресне мәшһүр мәгърифәтчебез Ризаэтдин Фәхретдин сүзләре белән тәмамлыйсым килә:

Онытмагыз динебезне,
Онытмагыз телебезне,
Юк үлмәсен, исән калсын
Татар дигән горур милләт.
Туа торсын бәбиләр дә,
Имин торсын гаиләләр дә
Мәңге – мәңге гомер итсен
Татар дигән горур милләт.

**V Билгеләр кую.**

**VI Өй эше. Слайдта күрсәтелә.**

1. “Әхмәдулланың кичерешләре”темасына инша язарга.
2. Татар халкының тагын нинди милли киемнәре бар? Шулар турында белешмә әзерләп килергә.
3. Хикәяне дәвам итәргә.